КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 30 март г.Казань № б-523

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестры турында» 2021 елның 30 июлендәге 1290 номерлы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестрын алып бару тәртибе турындагы нигезләмәнең 13 пункты нигезендә:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларын (алга таба – коммерциягә карамаган оешмалар) социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестрына (алга таба – реестр) кертүгә Татарстан Республикасы вәкаләтле органы итеп;

Министрлыкның икътисад һәм социаль өлкә тармакларын үстерү бүлеге башлыгын һәм Министрлыкның икътисад һәм социаль өлкә тармакларын үстерү бүлеге башлыгы урынбасарын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестры турында» 2021 елның 30 июлендәге 1290 номерлы карары белән расланган Коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмалар реестрын алып бару тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 6 пунктында каралган коммерциягә карамаган оешмалар турында белешмәләргә кул куюя һәм аларны Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге мәгълүмат системасына (алга таба – мәгълүмат системасы) кертү өчен җаваплы итеп;

Министрлыкның икътисад һәм социаль өлкә тармакларын үстерү бүлегенең әйдәүче консультантын Нигезләмәнең 6 пунктында каралган коммерциягә карамаган оешмалар турындагы белешмәләрне мәгълүмати системага кертү өчен җаваплы итеп;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүче коммерциягә карамаган оешмаларны реестрга кертүгә Татарстан Республикасы вәкаләтле органы итеп.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче коммерциягә карамаган оешмалар турындагы белешмәләрне Министрлыкка бирү өчен җаваплы затларны билгеләргә.

3. Министрлыкка Нигезләмәнең 6 пунктында каралган коммерциягә карамаган оешмалар турында булдырылган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген, шулай ук аларны реестрга үз вакытында кертүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин